**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XI УТЫРЫШЫ**

# К А Р А Р № 21

Яңа Усы авылы «14» май 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында»гы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 октябрендәге 103 нче номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236 номерлы Россия Федерациясе Законы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында»гы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 октябрендәге 103 нче номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 1.7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 нчы абзацны өстәргә:

«инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан башкарыла торган җирлектә;».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы: Г.С.Романова**